**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ГЛАВА ТЮРНЯСЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТӨРНӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Төрнәс ав. **КАРАР**

« 07 » ноябрь 2023 ел № 1

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 18 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Кызыл Армия урамы 25нче йорт адресы буенча урнашкан ФАП янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Көнчыгыш, Юл буе, Кызыл Армия, Кутузов, Суворов, Ворошилов, Көнбатыш, Совет, Көнбатыш тыкрыгы, Совет тыкрыгындагы йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә
2. 2023 елның 18 ноябренә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Яшьләр урамы буенча 6нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Яшьләр, Кыр урамнарындагы йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2023 елның 18 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Мәктәп урамы 54нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Мәктәп урамы, Завод урамы, Мәктәп тыкрыгы урамнарындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. 2023 елның 18 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Үзәк урам буенча 51нче йорт адресы буенча урнашкан авыл җирлеге бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Үзәк урамы, Елга

Арьягы урамы, Күл урамы, Бакча урамнарындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен Төрнәс авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы

- Төрнәс торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм таш җәю;
- Төрнәс авылында урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;
- Төрнәс авылындагы юлларны сезонлы карап тоту;
- Төрнәс авылында Җиңү паркын төзекләндерү;
- Төрнәстә су белән тәэмин итү чыганакларын норматив хәлгә китерү (янгын гидрантлары өчен коелар, скважиналарны лицензияләү).
- Тагылмалы янгын сүндерү су сыешлыгын сатып алу;
- Бакча, Мәктәп, Үзәк урамнарын төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

9. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В. Белов